Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2025 ел № 2

2025 елнын 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнен бердэм системасында жирле узидарэне оештырунын гомуми принциплары турында”гы Федераль законнын 45, 69 статьялары, 2004 елнын 28 июлендэге “ТатарстанРеспубликасында жирле узидарэ турындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы, Тукай муниципаль районынын “Борды авыл жирлеге” муниципаль берэмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районынын Борды авыл жирлегенен 07.11.2019 ел 51/1 номерлы “Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районынын Борды авыл жирлеге составына керуче торак пунктларда гражданнар жыенын эзерлэу хэм уткэру тэртибе турында нигезлэмэне раслау хакында”гы карары нигезендэ Борды авыл жирлеге Борды авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Борды авыл җирлеге Борды авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзеклэндеру, ремонтлау)

2. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Борды авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова